**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**АПАС ШӘҺӘР ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

**КАРАРЫ**

2021 ел, 15 гыйнвар №22

**«Апас шәһәр җирлеге муниципаль хезмәткәренә тиешле еллар эшләгән өчен пенсиягә чыгуга бәйле рәвештә һәм Апас шәһәр җирлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүче затларга муниципаль вазыйфадан пенсиягә чыгу сәбәпле бер тапкыр бирелә торган акчалата бүләкне түләү тәртибе турында» гы kararга үзгәрешләр кертү хакында**

2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы кодексы нигезендә, Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Апас шәһәр җирлеге Советы карар **бирә**:

1.Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Апас шәһәр җирлеге Советының 2018 елның 18 маендагы 117 номерлы «Апас шәһәр җирлеге муниципаль хезмәткәренә тиешле еллар эшләгән өчен пенсиягә чыгуга бәйле рәвештә һәм Апас шәһәр җирлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүче затларга бер тапкыр бирелә торган акчалата бүләкләү, муниципаль вазыйфадан пенсиягә чыгу сәбәпле, бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү тәртибе турында» гы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 )1 нче кушымтада:

1.7 пунктының җиденче абзацын төшереп калдырырга.

2 )2 нче кушымтада:

1.4 пунктының алтынчы абзацын төшереп калдырырга

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм җирлекнең мәгълүмат стендларында бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны «Апас шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге башлыгы урынбасары Н.Т. Исмәгыйлевка йөкләргә.

**Татарстан Республикасы**
**Апас муниципаль районы**
**муниципаль берәмлеге Башлыгы**
**Апас шәһәр җирлеге Башлыгы Р.Ф. Хисамутдинов**